**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ АКТАНЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

пр. Ленина, дом 17, с. Актаныш, 423740

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АКТАНЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

Ленин пр.,17 йорт, Актаныш ав., 423740

Тел. (85552) 3-44-22, факс (85552) 3-44-14, E-mail: mail.aktanysh@tatar.ru, www.aktanysh.tatarstan.ru

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

____________ № _____

**Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы «Такталачык төп гомуми белем бирү мәктәбе " муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесенең структур бүлекчәсе «Уразай балалар бакчасы» мәктәпкәчә белем бирү учреждениясен бетерү турында**

Россия Федерациясе Гражданлык кодексының 61-64 статьяларына, «Россия Федерациясендә бала хокукларының төп гарантияләре турында» 124-ФЗ номерлы Федераль законның 13 статьясына, "Россия Федерациясендә мәгариф турында" 29.12.2012 елгы 273-ФЗ номерлы Федераль законның 9 статьясындагы 1 өлешенең 4 пунктына таянып, Актаныш муниципаль районы муниципаль белем бирү оешмасын үзгәртеп кору яки бетерү турында 2026 елның 31 июленнән карар кабул итү нәтиҗәләрен бәяләү комиссиясенең 33 номерлы бәяләмәсе нигезендә

**КАРАР БИРӘМ:**

1. Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районының «Такталачык төп гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесенең структур бүлекчәсе «Уразай балалар бакчасы» мәктәпкәчә белем бирү учреждениясен 2026 елның 30 сентябреннән бетерергә.

2. «Такталачык төп гомуми белем мәктәбе» муниципаль бюджет гомуми белем учреждениесе директоры А.С.Хаҗиевка:

- Актаныш муниципаль районының «Такталачык төп гомуми белем мәктәбе» муниципаль бюджет гомуми белем учреждениясе уставына үзгәрешләр проектын әзерләргә;
- хезмәт законнары нигезендә, бетерелә торган белем бирү учреждениясе штатларын кыскарту процедурасын үткәрүне тәэмин итәргә;
- Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районының «Такталачык төп гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениясенең структур бүлекчәсе «Уразай балалар бакчасы» мәктәпкәчә белем бирү учреждениясен законда билгеләнгән тәртиптә тиешле хезмәтләрдә бетерергә.

3. Әлеге карарны Актаныш муниципаль районының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә түбәндәге адрес буенча: http://pravo.tatarstan.ru бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Актаныш муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары Д.М.Әнвәровага йөкләргә.

Җитәкче И.Ш. Бариев